Исполнительный комитет
Бизякинского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан
ул. Центральная д. 46, с. Бизяки
Менделеевский район, 423648

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә
Үз җирлеге башкарма комитеты
Үзәк урамы, 46, Бәзәкә авылы,
Менделеевск районы, 423648

тел./факс (85549)3-47-34

Постановление | Карар

07.03.2023 ел | № 9

Хөкем ителүчеләрне
мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә
җәза үтәү урыннарын билгеләү турында

Россия Федерациясе Җинаять кодексының 49 һәм 50 статьялары, Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексының 25 һәм 39 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты мәҗбүри эшләр һәм төзәтү эшләре рәвешендәге җинаять җәзасын үтәүне тәэмин итү максатларында

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендәге җәзаны үтәү өчен урыннар исемлеген 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә хөкем ителүчеләрне төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәү урыннары исемлеген 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И.Кәшәфетдинов

Килештерелде

"Татарстан Республикасы буенча җәзаларны
үтәү федераль хезмәте идарәсе
җинаять-башкарма инспекциясе"
Федераль казна учреждениесенең
Менделеевск муниципальара
филиалы башлыгы И.Г.Сәләхов

Килештерелде
"Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәү федераль хезмәте идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе" Федераль казна учреждениесенең Менделеевск муниципальара филиалы башлыгы
________________ел

И.Г. Сәлахов

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның 7 нче мартында
Карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә
мәҗбүри эшләр рәвешендәге җәзаны үтәү өчен
урыннар исемлеге

| № т/б | Оешманың исеме | Адресы | Эш төрләре |
|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы, Бәзәкә авылы, Үзәк урам 46, һәйкәл янындагы мәйдан | Территорияне җыештыру, очраклы чүп-чар җыю, кар җыю, кар өемнәре, чүп-чарны төяү һәм бушату |

Килештерелде
"Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәү федераль хезмәте идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе" Федераль казна учреждениесенең Менделеевск муниципальара филиалы башлыгы
_______________ел

И.Г. Сәлахов

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның 7 нче мартында
Карарына 2 кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә
төзәтү эшләре рәвешендәге җәзаны үтәү өчен
урыннар исемлеге

| № т/б | Оешманың исеме | Адресы |
|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы, Бәзәкә авылы, Үзәк урам 46, һәйкәл янындагы мәйдан. |